Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Рус Акташы авыл Советы

КАРАРЫ

«20» декабрь 2021 ел №31

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Рус Акташы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге тарафыннан шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру буенча Әлмәт районы Советы тәкъдимен кабул итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Әлмәт муниципаль районының «Әсәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2015 елның 6 маендагы 468 номерлы карары белән расланган вәкаләтләрнең бер өлешен Әлмәт муниципаль районы территориясендә урнашкан Әлмәт муниципаль районының җирле үзидарә органнары белән җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән килешүләр төзү тәртибе нигезендә

Рус Акташы авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру буенча Әлмәт районы Советы тәкъдимен Рус Акташы авыл җирлегенең Рус Акташы авыл Советы тарафыннан расланган Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү өлешендә кабул итәргә.

2. Рус Акташы авыл Советына Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан Рус Акташы авыл җирлеге бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру турында Әлмәт муниципаль районы Советы белән килешү төзергә.

3. Әлеге карарны Әлмәт районы Рус Акташы авылы Тозүчелер урамы 14 нче йорт, Акташ станциясе - контора бинасы торак пунктлар территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында»

(PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга,

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Рус Акташы авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Рус Акташы авылы
башкарма комитеты башлыгы С.А. Белоногов